ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.05.2022 ел Баулы шәһәре №81

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану буенча, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча, бакча йортын торак йорт дип һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 2 февралендәге 3 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану буенча, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча, бакча йортын торак йорт дип һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 2 февралендәге 3 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән» сүзләрен преамбулада төшереп калдырырга;

Административ регламент турында (карарга кушымта):

2нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.8.2. «Бакча йортын торак йорт яисә торак йортны бакча йорты дип танудан баш тарту өчен нигезләр» пунктын түбәндәге эчтәлекле ж) пунктчасын өстәргә:

«ж) бакча йортын су басу зонасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлегендә урнаштыру (бакча йортын торак йорт дип тану турында гаризаны караганда).».

2. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 137 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гузаиров